# ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“29” март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 29 мартында 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Иске Шимбер торак пунктында гражданнар Җыенының 23.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, (Иске Шимбер авылы зиратын төзекләндерү (чүп контейнерлары сатып алу));
2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (Иске Шимбер авылының М.Җәлил урамындагы урам юлларын ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); (грейдирлау, Иске Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 34 (утыз дүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 21 (егерме бер) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 21 (егерме бер) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Иске Шимбер торак пунктында гражданнар Җыенының 23.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, (Иске Шимбер авылы зиратын төзекләндерү (чүп контейнерлары сатып алу));

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (Иске Шимбер авылының М.Җәлил урамындагы урам юлларын ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); (грейдирлау, Иске Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү))

мәсьәләсе буенча карарны таныргa.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Иске Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.